
# Җөмлә кисәкләрен кабатлау

*7 нче сыйныфта*

*татар теле дәресе*


Баш кисәкләр
ия
Гади ия
Тезмә ия
хәбәр
Фигыль хәбәр
Исем хәбәр
Гади хәбәр
Кушма хәбәр
Тезмә хәбәр

# Иярчен кисәкләр

- Аергыч
  - тиңдәш
  - Тиңдәш булмаган
- Тәмамлык
  - туры
  - кыек
- Хәл
  - Урын хәле
  - Вакыт хәле
  - Рәвеш хәле
  - Күләм хәле
  - Сәбәп хәле
  - Максат хәле
  - Шарт хәле
  - Кире хәл
- Аныклагыч

| Җөмлә кисәк-ләре № | Ия | Хәбәр | Аерым-ланган хәл | Тәмам-лык | Аергыч | Урын хәле | Рәвеш хәле | Анык-лагыч |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | | | | | | | | |
| **2** | | | | | | | | |
| **3** | | | | | | | | |
| **4** | | | | | | | | |
| **5** | | | | | | | | |
| **6** | | | | | | | | |
| **7** | | | | | | | | |
| **8** | | | | | | | | |
| **9** | | | | | | | | |

1. Миңа* яңа бүрек, яңа киез ката, яңа бишмәт алып кайткан.
2. Иртә белән торгач*, үземне бер кара* өй эчендә күрдем.
3. Мин исә уракка* бармый идем*.
4. Беркөнне бабай*, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, авылыбыздан Казанга бара торган бер ямщикка мине утыртып, Казанга озаткан.
5. Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк*, күлмәкчән көенчә тышка чыгам* икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән.
6. Алар, әбәттән (көндезге аштан*) соң ишекне бикләсәләр дә*, минем ашарга кайтасымны белеп, ян тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде.
7. Әни мине тапшырып үзе киткәч, мин кызлар белән бергә "әлеп, би, ти, си, җом, хи"ны бер дә тартынмыйча* кычкырып укый башладым.
8. Бу яңа* ата-анамның хәлен дә бераз язып китим әле.
9. Шунлыктан минем капчыгым буялган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә* дә кайтып кердем.



*Татар халкының бөек шагыйре Габдулла  Тукайның тууына 130 ел*

# Җөмләләрдән хәлләрнең 8 төрен табарга

1.Суда аккошлар йөзә.

2.Бала кечкенә вакытта беләккә авыр, үскәч йөрәккә авыр.

3.Соңга калган өчен, ул шелтәгә эләкте.

4. Аны күрер өчен, бик биеккә күтәрелергә кирәк.

5. Ул бик тәэсирләнеп, дулкынланып тыңлый.

6.Бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк.

7.Әгәр мине бик сагынсаң, аккан суларга кара.

8.Ничаклы тырышса да, артык сикерә алмаячак.

# Өй эше

1) 227  нче күнегү(1 вариант)

2) Табигать күренешләрен тасвирлап, иҗади эш башкарып, бер җөмләне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерергә. (теләк буенча)



Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле.

Габдулла Тукай. 1913 ел.